OMEGA
OFFICIAL TIMEKEEPER
КӨН СӘГАТЬ МИНУТ СЕКУНД
2015 ЕЛГЫ СУ СПОРТ ТӨРЛӘРЕ БУЕНЧА 16 НЧЫ ФИНА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫНА КАДӘР



# АКШ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ КАТНАШ ЭСТАФЕТАДА ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 4Х100 ДИСТАНЦИЯГӘ ЙӨЗҮДӘ АЛТЫН МЕДАЛЬ ЯУЛАДЫ

08.08.2015, 19:23
СПОРТ

**Әлеге минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында бүгенге көннең соңгы финал йөзеше тәмамланды. Катнаш эстафетада ирекле стиль белән 4х100 дистанциягә йөзү буенча планетаның 8 иң әйбәт җыелма командалары ярышты.**

Иң көчле команда булып америкалылар билгеләнде - алар 3:23.05 секундлы нәтиҗә күрсәтте һәм лаеклы рәвештә алтынны гына яулап калмады, ә дөнья рекордын да яңарттылар. Алар артыннан ук финишка Нидерланд командасы килде һәм 3:23.17 секундлы нәтиҗә күрсәтте. Призлы өчлекне Канада җыелма командасы япты, аларның күрсәткече - 3:23.59 секунд.

ДЧ-2015. Йөзү

Катнаш эстафета. Ирекле стиль, 4х100 м.

1. АКШ - 3:23.05

2. Нидерланд - 3:23.17

3. Канада - 3:23.59

8 август. Казан. "Казан Арена"

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА